РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ГЛАВА
ГОРОДА ЧИСТОПОЛЬ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШЛЫГЫ**

***Постановление*** ***Карар***

**2024 елның 20 ноябре** **Чистай шәһәре** **№ 27**

«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советының «Чистай шәһәрен
төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»
2013 елның 4 июнендәге 22/2 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы
карары проекты буенча ачык тыңлаулар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 июнендәге 26/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Чистай шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 4 июнендәге 22/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары проекты буенча 2024 елның 17 декабрендә 11.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар билгеләргә: Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 йорт, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының конференц-залында.

2. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне, шулай ук чыгыш ясау хокукы булган гаризаларны язма рәвештә

кертергә һәм түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Чистай шәһәре, Карл Маркс урамы, 46, Чистай шәһәр Советы, 10 нчы каб. яисә 5-27-27 факсы буенча. Чыгыш ясау хокукы булган тәкъдимнәр, искәрмәләр, гаризалар эш көннәрендә 8 дән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Чистай шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 4 июнендәге 22/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын (алга таба оештыру комитеты) түбәндәге составта төзергә:

Ксенофонтов М.И. - Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары;

Добронравова О.В. - Чистай шәһәр Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

Камалов Р.Р. - 17 нче сайлау округы депутаты, оештыру комитеты секретаре;

Малхасян Т.В. - «Водников поселогы» 7 нче ТИҮ җитәкчесе, оештыру комитеты әгъзасы;

Хаматов А.Р. - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, оештыру комитеты әгъзасы;

Филиппова А.Ю. - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы баш белгече, оештыру комитеты әгъзасы.

4. Әлеге карарны һәм «Чистай шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы карарына билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2013 елның 4 июнендәге 22/2 номерлы карары проектын бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов